*Мәктәп туры*

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
**ТАТАР ӘДӘБИЯТЫННАН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕ**
(2024-2025 нче уку елы)
**6 нчы сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 120 минут**
**Максималь балл – 30**

**1. Мәзәкләр турында исеңә төшер. Аларны кайчан сөйлиләр? Мәзәкләр турында белгәннәреңне яз. (5 балл)**

**2. Рәсемне кара. Ул кайсы әсәргә ясалган? Әсәрнең исемен, авторын яз. Геройларын ата. (5 балл)**



**3. Фәнис Яруллин әсәрен билгелә. (1 балл)**

а) «Яз башы»

ә) «Зәңгәр күлдә Ай коена»

б) «Чыбыркы»

в) «Патша белән карт»

**4. Шигырьнең исемен, авторын яз. Шигырьне тулысы белән искә төшереп, анда бирелгән төп хис-кичерешне билгелә. (5 балл)**

– «Сез кайсы халыктан?» – дисәләр,
Батырлар исемен атадым.
Батырлар утларга керделәр,
Тик исән булсын, дип, Ватаным.

Илемнең хуҗасы булганга,
Мин җиргә нык басып атладым.
Кешеләр күтәрде Ватанны,
Кешене күтәрде Ватаным.

Мин күрдем, төннәрне таратып,
Дөньяда алсу таң атканын.
Яктыра, аллана җир йөзе…
Тан булып нур сибә Ватаным.

**5. Портретка игътибар ит. Биредә кем сурәтләнгән? Бу шәхес турында өч фактны искә төшереп яз. (6 балл)**



1) ____________________________

2) ____________________________

3) ____________________________

**6. Чит илне макта, үз илеңдә яшә, диләр. Бу дөресме? Бу турыда фикерләреңне яз, әдәбияттан мисаллар китерергә дә онытма. (8 балл)**